Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Нәдер авыл Советы

КАРАР

23 апрель 2025 ел

№ 128

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Яңа Нәдер авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә)

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын кертеп, график сурәте белән бергә, «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Әлмәт районы Яңа Нәдер авылы, Совет урамы, 81 йорты торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Яңа Нәдер
авыл җирлеге башлыгы С.М. Миннебаев

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Нәдер авыл Советының
2025 ел 23 апрель № 128
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

Яңа Нәдер 1 нче номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 106 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Х.Рахманов урамы, М.Җәлил урамы, Ш.Усманов урамы һәм С.Сөләйманова урамы).

Яңа Нәдер 2 нче номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 110 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Полевая урамы, Сөембикә урамы, Яшьләр урамы һәм Киров урамы буенча 35А дан 55 кә кадәр йортларның так ягы).

Яңа Нәдер 3 нче номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 121 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Тукай урамы буенча 44, 46, 50 нче йортлар, 52 нче йорттан 67 нче йортка кадәр, Киров урамы буенча 25, 20, 22 нче йортлар, 24 нче йорт 1 ф., 26 нчы йорт 1 ф., 26 нчы йорт 2 ф., 27, 29, 31 А йортлары, Киров урамы буенча 32 нче йорттан 48/2 нче йортка кадәр җөп ягы, Газиз Абдуллин урамы буенча 1 нче йорттан 18 нче йортка кадәр).

Яңа Нәдер 4 нче номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 125 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Тукай урамы буенча 1 нче йорттан 44 нче йортка кадәр, 45, 47А, 49, 51 нче йортлар һәм Совет урамы 1 нче йорттан 11 нче йортка кадәр).

Яңа Нәдер 5 нче номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 115 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Совет урамы буенча 12 нче йорттан 49 А йортына кадәр, Озерная урамы буенча 1 А йортыннан 12 нче йортка кадәр)

Яңа Нәдер 6 нчы номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 119 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Совет урамы буенча 50 нче йорттан 118 нче йортка кадәр).

Яңа Нәдер 7 нче номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 121 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Партизан урамы, Киров урамы буенча 14, 17, 21нче йортлар, Совет урамы буенча 120 нче йорттан 180 нче йортка кадәр).

Яңа Нәдер 8 нче номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 124 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Куйбышев урамы 60 нчы йорттан 120А йортына кадәр, Лесная урамы, Зәй урамы).

Яңа Нәдер 9 нчы номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 114 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Куйбышев урамы 8 нче йорттан 59 нчы йортка кадәр).

Яңа Нәдер 10 нчы номерлы бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны – 106 кеше.

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Нәдер авылы (Киров урамы буенча 1 нче йорттан 13 нче йортка кадәр, Речная урамы, Пионер урамы 1 нче йорттан 15 нче йортка кадәр, Комсомол урамы буенча 1 нче йорттан 7 нче йортка кадәр , Куйбышев урамы буенча 1 нче йорттан 7 нче йортка кадәр).

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Нәдер авыл Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте

| Округ № | Бермандатлы сайлау округы исеме |
|---|---|
| 1 | Яңа Нәдер |
| 2 | Яңа Нәдер |
| 3 | Яңа Нәдер |
| 4 | Яңа Нәдер |
| 5 | Яңа Нәдер |
| 6 | Яңа Нәдер |
| 7 | Яңа Нәдер |
| 8 | Яңа Нәдер |
| 9 | Яңа Нәдер |
| 10 | Яңа Нәдер |

